# БАЛАМ ТӘРБИЯЛЕ БУЛСЫН, ДИСӘҢ…

Балага белем һәм тәрбия бирү – иң кыен, четерекле эш. Бу гасырлар буе шулай булган һәм киләчәктә дә шулай булыр. Ул – мәңгелек мәсьәлә. Бер генә ата – ана да бала тәрбиясен читләтеп үтә алмый. Һәркайсыбыз бу гаять җаваплы эшнең ачысын-төчесен татырга мәҗбүр. Берәүләргә ул җиңелрәк бирелә, аларның балалары яхшы тәрбия алып үсә. Андый ата-ана өчен бала бәхет һәм шатлык чыганагына әверелә.

Икенчеләргә, киресенчә, балакагы-хәсрәт китерә.

Моның билгеле бер сәбәпләре бар. Кайбер ата-аналар баланы мәктәпкә әзерләүгә, укытуга, аны тәрбияләүгә җиңел карыйлар, аны икенче, өченче дәрәҗәдәге эш,хәтта тәрбияче, укытучы эше дип санаучылар  да бар.

Безнең көннәрдә балага белем һәм тәрбия бирүдә гаиләнең әһәмияте бик нык артты. Гаилә ул – җылы учак. Гаилә никадәр нык булса, аннан килгән җылылык та шулкадәр көчле була. Гаиләнең терәге ир-ат – әти кеше. Ә ана кеше үзенең бөтен булган күңел байлыгын, матурлыгын үз нарасыена бирә.

Кече яшьтәге балалар бик кызыксынучан була. Алар ата белән ана алдына кырыкмаса кырык төрле сорау куялар. Ата-анасының барлык сорауларга да җавап биреп бетерергә я вакыты булмый, я теләми.

Галимнәр шушы мәсьәлә белән кызыксынганнар. Берничә ананың һәм баланың киеменә микрофон һәм тавыш язу аппараты куйганнар. Нәтиҗәдә: 4 яшьлек бала көнгә уртача 440 ка якын сорау биргән. Алар өлкәннәр башына килмәгән сораулар да яудыралар: ни өчен чеби сары була, ә тавык сары түгел, нигә куянның колагы озын, койрыгы кыска, ни өчен кара тавык кара йомырка салмый һ.б. бала фиизк яктан да, акыл ягыннан да үсә, белем һәм тәҗрибә туплый. Шуңа күрә ул күп нәрсә белән кызыксына, белмәгәнен сорый, таләп итә, йөдәтә, хәтта тупаслык та эшли. Бу – аның табигый ихтыяҗы.

Тәҗрибәле ата-аналар моңардан бик оста файдаланалар. Үзләре җавап таба алмаган сорауларга яки булдыра алмаган эшләрне башкарырга ярдәм итәргә әзер торучы никадәр балалар өчен клублар, түгәрәкләр эшли бит. Әти-әниләрнең күбесе кече яшьтән үк баланың сәләтен, кызыксынуын исәпкә алып аны бассейннарга, спорт комплексларына, сәнгать, музыка, хореография мәктәпләренә, төрле түгәрәкләргә йөртәләр. Ягъни баланың шул кызыксыну

үзенчәлегенә вакытында дөрес юнәлеш бирәләр. Бу бик мөһим, чөнки тора-бара аның кызыксынуы бик тиз сүрелергә дә мөмкин.

Шагыйрь М.Сөндекле “Бала күңеле” исемле шигырендә бу хакта болай ди:

Бала күңеле – нәфис ак кәгазь,
Әле бит ул каләм күрмәгән.
Әле беркем аның күңелендә
Тылсымлы эз салып йөрмәгән.

Дөнья яңа яуган ак кар –
Тели бала барын аңларга.
Тәүге юлны бала күңеленә
Ата – ана тиеш язарга.

Бик дөрес. Әмма “бала күңеле” дигәннән нәрсә аңларга? Ул, чыннан да, каләм күрмәгән ак кәгазь генәме? Әллә аңарда тагын да берәр хикмәт яшеренгәнме? Әйе. Яшеренгән шул. Биредә мәсьәләнең ике ягы бар. Беренчесе – нәселдәнлек, тумыштан килә торган сәламәтлек билгеләре; икенчесе – бала тугач, аны әйләндереп алган социаль тирәлек бирә торган белем – тәрбия һәм тормыш тәҗрибәсе. Бала чын кеше булып үссен өчен аңа барлык төр: физик, эстетик, әхлак хезмәт тәрбиясе кирәк. Тәрбия төрләренең берсе генә дә дөрес бирелмәгәндә дә баланың әхлакый сыйфатларына зыян килүе ихтимал. Әйтик, физик һәм хезмәт тәрбиясе көч һәм бәхет чыганагы булып тора. Хезмәткә өйрәнеп үсмәгән баланың эш сөючән, киләчәктә ата – анасына ярдәмче, terәк булачагы бик шикле.

Әйе, балага шулкадәр күп тәрбия бирү кирәклегенә гаҗәпләнергә ярамый. Кайвакытны ата-аналардан: “Безне тәрбияләүчеләр дә булмады, үзебез укыдык, “Дәрес эшлә!” – диюче юк иде, барысын да үзебез эшли идек”, - дигән сүзләр ишетергә туры килә. Киресенчә, хөрмәтле ата-аналар, безне дә тәрбияләгәннәр, ләкин аз сүз блән. “Алма агачыннан ерак төшми”, ди халык. Бу сүзләрдә дә хаклык бар. Чөнки без телибезме, теләмибезме, үз үрнәгебез белән дә балага йогынты ясыйбыз. Менә шуңа күрә дә һәр ата-ана үз гамәлләренә, сөйләшү, үз-үзен тотышына игътибар итәргә тиеш.

Бала – ата-ананың көзгесе бит. Ул нәрсә күрсә, шуны кабатлый. Кыз бала әнисенә ошарга тырыша, ә ир бала – әтисенә.

Бабаларыбызның “оясында ни күрсә – очканында шул була”, - дигән акыллы сүзләрен бер генә минутка да онытырга ярамый.

Бала тәрбияләүдә, аның чын кеше булуында тагвн бер әһәмиятле мәсьәләне читләтеп үтү мөмкин түгел. Сүз – гаилә әгъзалары арасында бердәм таләп булдыруның әһәмияте турында бара. Бердәм таләп булмаудан бала

ялагай, эгоист булып үсә. Әни кеше баланың гаепләрен атадан яшерсә, тора-бара бала этисен дә, әнисен дә тыңламый башлый.

Гаилә – бердәм, дус булырга тиеш. Кешенең бәхет ачкычы һәрвакыт үз кулында. Балаларга дөрес тәрбия бирү, үз бәхетеңә ышанычлы нигез салу дигән сүз ул.

Тәрбия булган урында тәртип бар, тәртип булса мәктәпкәчә яшьтәге баланың танып-белү процессын үстерү мөмкинчелеге тагын да арта. Безнең балалар бакчасында балаларны мин һич кенә дә тәртипсез, дип әйтмәс идем. Искиткеч итагәтьле балалар, гаиләләр күп. Әмма шулар арасында (акны – ак, караны – кара дип әйтик инде) тәртипсез яклары белән башкалардан аерылып торучылар да юк түгел баланы артык ярату, аның барлык сорау-таләпләрен дә үтәргә тырышу һәрвакытта да уңай нәтиҗә бирми.

Элекке заманнарда мәктәп-мәдрәсәләр уку-укыту эшен халык педагогикасына таянып оештырганнар. Соң булса да уң булсын дип, безгә дә шушы халык педагогикасы кагыйдәләрен, кануннарын, алымнарын өйрәнергә һәм көндәлек тормышта файдаланырга кирәк. Халык педагогикасының асылы нидән тора соң?

- Ана хакы, ата хакы, күрше хакы дус-иптәш хакы, юксыллар хакы. Нинди гамәлләрне эшләргә ярамаганлыгын кечкенәдән үк төгәл аңлатырга кирәк.
- Ризык хәрәмы – аракы, тәмәке, наркотиклар;
- Киемдәге хәрәм – ярым ялангач калдырып тегелгән киемнәр;
- Иҗтимагый хәрәм – отышлы уеннар, сихерләү, исраф итү, үз-үзеңә кул салу;
- Хисси хәрәм – гайбәт сөйләү, кеше намусын кимсетү, хурлау;
- Рухи хәрәм – эти-әнигә буйсынмау, ялганлау, үч саклау, кушамат тагу, гаеп эзләү, икейөзлелек, әманәткә хыянәт итү һ.б.

Әби-бабайлар менә бу санап кителгәннәрне балаларга кече яшьтән үк даими рәвештә җиткергәннәр, гамәли гадәткә әверелдергәннәр. Күп очракта аларны дин белән бәйләп өйрәткәннәр.

Бала холкына иң элек гаиләдә нигез салына. Бала күп вакытын эти-әниләре янында үткәрә. Аларның үзара мөнәсәбәтләрен күреп үсә, гадәтләрен, сөйләгән сүзләренә хәтле күңеленә сеэдереп бара.

Баланы теге яки бу эшкә өйрәтү күп вакытны ала, түзеилек тә җитеп бетми, киребеткән бала булса, аны җайларга, көйләргә дә кирәк. Шунлыктан әниләр күп нәрсәне, хәтта балалары үсеп җиткәч тә, үзләре эшләп куя. Тәртипле гаиләдә исә баланы эшкә өйрәтеп үстерүгә зур әһәмият бирәләр. Әйткәнне көтмичә, өоклаган урынын җыештырып, ашаганнан соң савыт-сабаны юып кую, өйдәге вак-төяк эшләрне эшләве, ул гынамы соң, әнисе пешергән ашны

мактый-мактый ашавы, өстәл артыннан рәхмәт әйтеп кузгалып китүе, йокларга ятканда хәерле төн теләве, барасы җиренә рөхсәт сорап китүе, исәнләшеп йөрүе – баланың кечкенәдән өйрәнгән, канына сеңгән гадәтләре булырга тиеш. Гаиләдә баланы дәрес өйрәткән кебек, утыртып озаклап үгет-нәсихәт җиткерүчеләр сирәктер. Баланы тәрбияләү эш арасында барса, үтемлерәк тә була. Балалар тиз үзләштерүчән, әмма тиз онытучан да булалар. Кат-кат әйтергә, игътибарга да өйрәтергә кирәк.

Һәр милләттә элек-электән килгән ырымнар, юрамалар, гыйбәрәләр бар. Элек без аларга дини хорафатлар дип кенә карый идек. Чынлыкта, һәркайсының төбендә тәрбия элементлары чткан бит. Мәсәлән, бала өстәл артында аягын селкеп утырса, “шайтан чакырма”, - дип кисәтү ясаганнар, теләмичә генә ашаса, яки ашын калдырса, “бәхетең югалыр”, - дигәннәр, кеше янында иснәп утырса, “авызыңны капла, шайтан керер”, - дип әйткәннәр, “яңагыңа таянма, атаң – анаң үлер”, -дигәннәр. Шулай итеп, әдәплелекнең иң гади кагыйдәләрен мисаллар аша, мифик образлар ярдәмендә өйрәткәннәр.

Балаларыбызның киләчәген алдан күреп, аны матур итәр өчен бөтен көчебезне куеп тырышыйк. Тегүче күлмәкне бозса, ул аны төзәтеп тегә, әмма тәрбиядә киткән ялгышлыкны төзәтү бик авыр. Шуны онытмыйк.